РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Площадь Победы, 4, город Бавлы, 423930

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ
Җиңү мәйданы, 4, Баулы шәһәре, 423930

Тел.: (85569) 5-29-50, факс: (85569) 5-38-72. E-mail: Bavly.Gorispolkom@tatar.ru, сайт: www.bavly.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_______________ г. Бавлы №______

2019 елның язгы чорында Баулы шәһәре
урам-юл челтәре буенча транспорт чаралары
хәрәкәтен вакытлыча чикләү үтәлеше

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 ст. 5 п., «Россия Федерациясендә автомобиль юлларының юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 ел, 8 ноябрь 257-ФЗ номерлы Федераль законга һәм «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 ел, 3 август 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына таянып, 2019 елның язгы чорында юл киеменең конструкциясе сәләте кимүгә бәйле рәвештә, урам-юл челтәренең һәм аларда юл корылмаларының сакланышын тәэмин итү максатыннан,

КАРАР БИРӘ:

1. Урам-юл хәрәкәтен саклауны тәэмин итү максатларыннан, 2019 елның 20 апреленнән 19 маена кадәр Татарстан Республикасы Баулы шәһәренең урам - юл челтәрендә рөхсәт ителгән 3.5 тонна автотранспорт чарасы һәм аннан күбрәк булган механик транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне билгеләргә.
2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән 2019 елның 19 маена кадәр Баулы муниципаль районының Баулы шәһәре урам-юл челтәре буйлап чылбырлы һәм тәгәрмәчле тракторларының йөрүен тыярга. Һава шартларына бәйле рәвештә, хәрәкәтне чикләү вакытын Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән үзгәрешләр кертергә мөмкин.

3. Транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында Баулы шәһәренең, Баулы муниципаль районының юл-урам челтәрләре буйлап йөрүне рөхсәт итәргә:

- пассажирлар ташучы җәмәгать транспорты;

- хезмәт күрсәтү буенча 01, 02,03,04 автотранспортлары;

- махсус транспортлар өчен: катнаш азык, орлыклар, ашлык, ашламалар, терлек, кош-корт, халык өчен киметелгән газ, сөт ташу, он ташу, почта автомобильләре;

- азык-төлек ( икмәк, он, макарон, сөт, атланмай, шикәр, тоз, ит, йомырка, чәй, яшелчә) ташу өчен махсус транспорт чаралары;

- шәһәр халкын тәэмин итү өчен дарулар ташучы автомобильләр;

- язгы кыр эшләрен башкару өчен ягулык-майлау материаллары ташучы автомобильләр;

- каты көнкүреш калдыкларын чыгаруга җәлеп ителгән махсус транспорт чаралары;

-табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә җәлеп ителгән автотранспорт чаралары;

-Татарстан Республикасының Баулы шәһәре «Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» муниципаль казна предприятиесе автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тотуны гамәлгә ашыручы махсус техника;

- төбәкнең муниципальара әһәмияткә ия булган гомуми файдалану юлларында йөрергә махсус рөхсәте булган автомобильләр.

4. Суворов, Зиновьев урамнары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләргә, федераль трасса ягыннан, Ваһапов, Муса Җәлил, Чапаев урамнары буенча «Биеклекне чикләү» 3.13 билгесе куярга, Беренче Май урамыннан 27 микрорайонга кадәр тимер-бетон блоклар һәм «Хәрәкәт тыелган» 3.2 юл билгесе куярга. Октябрь, Энгельс, Совет, Пл Октября, С. Сәйдәшев урамнары, 27 нче микрорайон, Садовая, Пушкин, Калинин урамнары ишегалларына керү урыннарына «Йөк күтәрүне чикләү» билгесен урнаштырырга.

5.Транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында транспорт чаралары хуҗалары яки кулланучылары кирәк булган очракта Баулы шәһәренең урам-юл челтәре буйлап йөрүне рөхсәт итәргә.

Баулы муниципаль районының 3.5 тонна һәм аннан максималь массасы күбрәк булган механик транспорт чарасының рөхсәт ителгән рәсмиләштерү юлы белән, Баулы муниципаль районының Баулы шәһәре урам-юл челтәре буйлап йөрү өчен, бердәм үрнәктәге махсус рөхсәт (пропуск) хәрәкәтне чикләүләр чорында бердәм үрнәктәге (даими), яисә бер тәүлеккә (бер тапкыр)

Баулы муниципаль районының Баулы шәһәре автомобиль юлларына китерелгән зыянны каплау шарты белән 1 нче кушымта нигезендә.

Билгеләргә:

1) максималь массасы 3.5 тонна һәм аннан күбрәк рөхсәт ителгән механик транспорт чаралары Баулы муниципаль районының Баулы шәһәре автомобиль юллары буйлап йөргән өчен зыянны каплау хисабынан түләнгән акчалар җирле бюджетка күчерелә.

2) пропускалар бирүдән алынган акчалар, чыгымнар сметасында билгеләнгән акчалардан тыш, түбәндәгечә бүленә:

80% - Баулы шәһәре юлларын төзекләндерү өчен җиһазлар һәм техника, материаллар сатып алуга бәйле чаралар , урам-юл челтәренә китерелгән зыянны компенсацияләүне финанслау;

20% - Баулы бүлегенең юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясенең юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны видеофиксацияләү приборларын сатып алу һәм транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү чорында тәүлек буе кизү торуны оештыру өчен.

6. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты һәм Баулы шәһәре муниципаль казна предприятиесе «Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе»нә:

- форманы эшләргә һәм бланкларны әзерләргә;

-2019 елның язгы чорында юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлеге белән берлектә механик транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне үтәүне контрольдә тоту өчен постлар җиһазларының санын, дисклокациясен һәм схемасын билгеләргә;

-2019 елның 20 апреленнән 19 маена кадәр «Россия Федерациясе автомобиль юллары буенча авыр йөкләрне ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау» турында 2009 ел, 16 ноябрь 934 номерлы РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, рөхсәт ителгән максималь массалы механик транспорт чаралары белән Баулы шәһәре автомобиль юллары буйлап йөрү өчен максималь дәрәҗәдә рөхсәт ителгән зыянны каплау күләмен билгеләргә;

- 4 нче пункт һәм ГОСТ 52289-2004 нигезендә тимер-бетон блокларын, биеклекләрне чикләү корылмаларын оештыруның башка чараларын урнаштыру.

7. Татарстан Республикасы Баулы шәһәренең урам - юл челтәре буенча йөрү хокукына Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Баулы шәһәренең «Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» МКП белән берлектә, пропуск бирүне йөкләргә.

8. Баулы шәһәренең «Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе», светофор хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче предприятие белән берлектә, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча дәүләт инспекциясе бүлеге белән килешү буенча хәрәкәтне чикләү билгеләрен билгеләргә.

9. Баулы эчке эшләр бүлегенең юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча дәүләт инспекциясе бүлегенә әлеге карар белән кертелгән чикләүләрнең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

10. Әлеге карарны Баулы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, «Татмедиа» ААҖ филиаллары, «Хезмәт даны» һәм «БРТ телерадиокомпаниясе» газетасы редакциясе аша халыкка җиткерү»

11.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Д.Л.Бакиров

Кушымта №1
ТР «Баулы шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы
Башкарма комитет җитәкчесе карарына

2019 елның 20 апреленнән 19 маена кадәр Баулы шәһәре урам - юл челтәре буйлап йөрү өчен максималь дәрәҗәдә рөхсәт ителгән 3.5 тонна һәм массасы күбрәк булган механик транспорт чараларының узу бәясе

**Бөтен чордагы чикләүләр:**

– 7200 сум-рөхсәт ителгән максималь массалы механик транспорт чаралары өчен 3.5 тоннадан 5 тоннага кадәр;

- 8550 сум-рөхсәт ителгән максималь массасы 5-7 тонна булган механик транспорт чаралары өчен;

- Рөхсәт ителгән максималь массасы 7-10 тонна булган механик транспорт чаралары өчен-11850 см.;

– 16500 сум-рөхсәт ителгән, максималь массасы 10нан 15 тоннага кадәр булган механик транспорт чаралары өчен;

- Максималь массасы 15 тоннадан 20 тоннага кадәр рөхсәт ителгән механик транспорт чаралары өчен 22800 сум;

- Рөхсәт ителгән максималь массасы 5-7 тонна булган механик транспорт чаралары өчен 31050 сум;

- 8550 сум-рөхсәт ителгән максималь массасы 20 тоннадан 25 тоннага кадәр булган механик транспорт чаралары өчен;

- Рөхсәт ителгән максималь массасы 25-30 тонна булган механик транспорт чаралары өчен 40950 сум;

- 51900 сум – рөхсәт ителгән максималь массасы 30-35 тонна булган механик транспорт чаралары өчен;

– Максималь массалы 35тән 40 тоннага кадәр булган механик транспорт чаралары өчен 64650 сум;
- Рөхсәт ителгән максималь массасы 40тан 45 тоннага кадәр булган механик транспорт чаралары өчен 80100 сум;

- 97650 сум-рөхсәт ителгән максималь массалы 45 тән 50 тоннага кадәр механик транспорт чаралары өчен;

**Бер тапкыр (24 сәгатькә гамәлдә):**

– Максималь массасы 3.5 тоннадан 5 тоннага кадәр булган механик транспорт чаралары өчен 240 сум;

–-рөхсәт ителгән максималь массасы 5-7 тонна булган механик транспорт чаралары өчен ;

- 395 сум-рөхсәт ителгән максималь массасы 7-10 тонна булган механик транспорт чаралары өчен;

- 550 сум-рөхсәт ителгән максималь массасы 7-10 тонна булган механик транспорт чаралары өчен;

– 760 сум-рөхсәт ителгән максималь массасы 15-20 тонна булган механик транспорт чаралары өчен;

- Рөхсәт ителгән максималь массасы 20 тоннадан 25 тоннага кадәр булган механик транспорт чаралары өчен 1035 сум;

– 1365 сум-рөхсәт ителгән максималь массасы 25-30 тонна булган механик транспорт чаралары өчен;

- 1730 сум – рөхсәт ителгән максималь массасы 30-35 тонна булган механик транспорт чаралары өчен;

– 2155 сум-рөхсәт ителгән максималь массасы 35тән 40 тоннага кадәр булган механик транспорт чаралары өчен;

- -рөхсәт ителгән максималь массалы 40тан 45 тоннага кадәр механик транспорт чаралары өчен;

- 3255 сум – рөхсәт ителгән максималь массалы 45-50 тонна механик транспорт чаралары өчен;